РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

РЕШЕНИЕ КАРАР

2023 елның 23 июне № 8

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре депутатына, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итүнең Кукмара шәһәре Советының 2022 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән расланган Тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре депутатына, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итүнең Кукмара шәһәре Советы карары белән расланган Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) (алга таба – Татарстан Республикасы Рәисе)» сүзләренә алыштырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алыштырырга;

5 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алыштырырга;

6 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алыштырырга.

7 пунктның беренче һәм өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алыштырырга.

11 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Рәисенә»дигән сүзләр белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Кукмара шәһәре мэры С. Д. Димитриев